Бүгенге санда | **Җирен теркәмәгәннәргә штраф яный 3 бит**

**Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын аң белән!**

# САРМАН

Сарман районы

Чәршәмбе
**25**
март, 2015

Газета 1931 елдан чыга
№ 21 (10483)



• ***БӘЙГЕЛӘР***

# Эшче һөнәрләрнең дәрәҗәсе үсә

**WorldSkills International – коммерция белән бәйле булмаган халыкара ассоциация. Аның максаты булып, бөтен дөнья буенча халыкара ярышлар үткәреп, һөнәри әзерлек һәм һөнәрчелек статусын һәм стандартларын күтәрү, эшче һөнәрләренең дәрәҗәсен һәм һөнәри белемне үстерү булып тора.**

2011 елның октябрендә Стратегик инициативалар агентлыгының күзәтү советы тарафыннан «Эшче һөнәрләре буенча Милли чемпионат үткәрү» проекты хупланды. Шул ук агентлык һәм Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы инициативасы буенча, 2012 елның апрель аенда Россиягә ассоциация Президенты Саймон Бартли сәфәр кылды. Нәтиҗәдә Россия WorldSkills International халыкара ассоциациясе составына кертелде. 2013 елда «WorldSkills Russia-2013 Милли чемпионаты» I бөтенроссия конкурсы Тольятти шәһәрендә үтте, 2014 елда чемпионатның икенчесе Казанда узды. Тольяттида җиңүчеләр Россия командасын – Германиядә, Казанда җиңүчеләр Франциядә тәкъдир иттеләр.

18 мартта Сарман аграр көллияте базасында «Тракторчы-механизатор» компетенциясе буенча WorldSkills Russia региональ чемпионатының сайлап алу туры үткәрелде. Татарстанның көллиятләрендә һәм техникумнарында мондый ярышлар февраль аенда башланды.

Автотрактор паркында узган ярышларда республиканың 25 районыннан студентлар катнашты. Сарман районы данын аграр көллият студенты Артур Шаймәрданов яклады. Артур, иң күп балл (94) җыючы булса да, чемпионатның сайлап алу туры хуҗалары ягыннан буларак, конкурстан тыш чыгыш ясады.


Автор фотосы

*Күбрәк фотоларны* ***sarman-rt.ru*** *сайтыннан карагыз.*

Студентлар дүрт модульдә көч сынаштылар: «МТЗ-82.1» тракторының электр җиһазларының техник яраксызлыкларын билгеләү һәм аларны бетерү», «МТЗ-82.1» тракторының двигателен тукландыру системасына техник хезмәт күрсәтү», «Д-243» двигателенең газ тарату механизмына техник хезмәт күрсәтү», «Тракторны фигуралы йөртү». Һәрбер модульгә экспертлар билгеләнгән иде: Тукай районы Новый поселогы урта гомуми белем бирү мәктәбе директоры Булат Мәхмутов, «Җәлил»агрофирмасының баш инженеры Марат Хәлиуллин, Зәй политехник көллиятенең укыту практикасы буенча директор урынбасары Фаяз Вәлиуллин һәм дәүләт техник күзәтчелеге идарәсенең Сарман районы бүлеге начальнигы Альберт Сәлахов. Сарман аграр көллияте укытучысы Илшат Гәрәев эксперт-методик советның рәисе, ярышларның өлкән эксперты булды. Чемпионатның сайлап алу турын оештыруда Сарман аграр көллияте директоры Зөбәер Әһелтдинов һәм аның урынбасары Илфат Нигъмәтуллин, көллият укытучылары һәм мастерлары Рөстәм Мәүләвиев, Фәнис Мөхәммәтшин, Ринат Гыйльфанов, Айрат Гарипов, Фәрхәт Исмәгыйлев һәм Динар Сәгыйтев катнаштылар.

Артур Шаймәрдановның конкурстан тыш катнашуын истә тотып, ярышларда беренче урын 93 балл җыйган Балык Бистәсе агротехник техникумы студенты Рамазан Гыймаевка бирелде. Кукмара аграр көллиятендә белем алучы Рөстәм Гайфетдинов, 90,5 балл җыеп, икенче урынга лаек булды, Зәй политехник көллияте студенты Алексей Кондратьев 90 балл белән өченче урынны алды.

Аерым номинацияләрдә җиңүчеләр дә билгеләнде. «МТЗ-82.1» тракторының электр җиһазларының техник яраксызлыкларын билгеләү һәм аларны бетерү» номинациясендә Лениногорск политехник көллиятенең Азнакай филиалында укучы Рамил Латыйфуллин, «МТЗ-82.1» тракторының двигателен тукландыру системасына техник хезмәт күрсәтү» номинациясендә Арча агросәнәгать һөнәри көллияте студенты Илназ Әхмәтханов, «Д-243» двигателенең газ тарату механизмына техник хезмәт күрсәтү» номинациясендә Алексей Кондратьев, «Тракторны фигуралы йөртү» номинациясендә Саба аграр көллияте студенты Галинур Ваесов җиңделәр.

Апрельдә ярымфиналга йомгак ясау кысаларында Милли чемпионатның финалында катнашучылар билгеле булачаклар. Эшче һөнәрләре буенча ярышларның ахыргы сериясе май аенда Казан шәһәрендә үтәчәк.

**Илназ СИРАЕВ**

## чәршәмбедән чәршәмбегә

**Рубрикабыз геройлары – яшәү рәвешләрен үрнәк итәрлек, тырыш хезмәтләре өчен республика, район җитәкчелегенең бүләкләренә лаек булган, төрле дәрәҗә бәйгеләрдә уңыш яулаган шәхесләр.**

## Рәфидә Диярова



Мөслим районының Мәлләтамак авылында туып-үскән кыз, 1980 елда Казан кооператив техникумын тәмамлый һәм юллама белән Сарман райпосына эшкә килә. Киләчәк язмышы Сарман белән бәйләнер дип, ул , бәлки, уйламагандыр да. Әмма райпога шулай ук юллама буенча эшкә килгән Мамадыш егете Дамир белән гаилә корып, алар Сарманда яшәп калалар, балалар үстерәләр, бүген инде оныклар сөяләр.

Рәфидә товар белгече булып эшли, соңрак универмаг директоры була. 2006 елдан исә Рәфидә эшмәкәр Нуруллинда өлкән товар белгече булып эшли. Эшен җиренә җиткереп башкара ул, нәтиҗәсе – район Советының, Татпотребсоюз һәм Роспотребсоюзның Мактау грамоталары белән бүләкләнүе. Ә 2010 елда РФ Кулланучылар җәмгыятьләренең үзәк берлегенең «За доблестный труд» күкрәк билгесенә лаек була. Менә юбилее уңаеннан да аңа муниципаль район Советының Мактау грамотасы тапшырылды.

**Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ** **sarman-rt.ru** **Реклама хезмәте телефоны: 8(85559) 2-57-76**

САРМАН
**Сарман районы газетасы**

**"ТАТМЕДИА" АҖ филиалы директоры – баш редактор А.Ә.Сабирова**

**Тел.: 2-40-31.**

**Редакциянең адресы:**
423350, Татарстан Республикасы, Сарман районы, Сарман авылы, Ленин ур., 17 йорт.
**Эл.адрес:** sarmangazetam11@mail.ru
**Телефоннар:**
2-42-35 – бухгалтерия (факс),
2-57-76 – реклама бүлеге,
2-42-33 – җаваплы секретарь, корреспондентлар,
2-52-10 – җирле радиотапшырулар редакциясе.
**Нәшир:** "ТАТМЕДИА" АҖ. 420097, Казан шәһәре, Академия ур., 2.

Газета массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендә законнарның үтәлешен күзәтү буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү турында таныклык ПИ № ТУ16-01013, 2013 ел, 16 май. Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Газета офсет ысулы белән җаваплылыгы чикләнгән "Глагол" җәмгыятендә басылды. ТР, Яр Чаллы шәһәре, Әлмәт тракты, 10 нчы йорт, 3 нче бүлмә.

Басырыга кул кую вакыты:
график буенча – 16.00 сәгатьтә.
нигездә (фактта) – 15.40 сәгатьтә.

татмедиа

Тираж – 3118 данә.

Редакциянең фикере һәрвакытта авторлар фикере белән аваздаш булмаска мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булу мөмкинлеге юк.
Кулъязмаларга бәяләмә язылмый һәм алар кире кайтарылмый.
Реклама игъланнарындагы мәгълүматның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.
Материаллар редакциянең язма рөхсәте белән генә күчереп бастырылырга мөмкин.

Газета атнаның чәршәмбе, җомга көннәрендә татар һәм рус телләрендә чыга.

Заказ № 2724

Газетага язылу индекслары: 16267, 16265.

Бәясе ирекле.

16+